**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының 8 нче сыйныф татар укучыларына татар әдәбиятыннан уку елы ахырында тестлар уздыру өчен контроль-үлчәү материалларының үзенчәлекләре (спецификация)**

**1. Эшнең максаты**

Уку елы ахырында 8 нче сыйныф укучыларына татар әдәбиятыннан тестлар эшләтү ел дәвамында үзләштергән материалны ачыклау, әдәбияттан белем дәрәҗәсен ачыклау максатыннан оештырыла.

**2. Эшнең төзелешен һәм эчтәлеген билгеләү принциплары**

Тест биремнәренең төзелеше һәм эчтәлеге уку елы ахырында укучыларның ел дәвамында татар әдәбиятыннан үзләштергән материалын мониторинглау, ачыклау, белем дәрәҗәсен объектив бәяләү мөмкинлеген бирә. Аның төзелеше һәм эчтәлеге максатка ярашлы, оптималь.

Тестларның формасы һәм төзелеше, биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе татар әдәбияты курсыннан шушы сыйныфта үзләштергән материалны яктырта. Аларның эчтәлеге укучыларның татар әдәбиятыннан үзләштергән теоретик һәм гамәли белем дәрәҗәсен, күнекмәләрен бәяләргә мөмкинлек бирә.

**3. Эшнең төзелеше**

Укучы, тестларга әзерләнү барышында, ел дәвамында өйрәнгән әсәрләрне, татар әдәбиятыннан үзләштергән материалны кабатларга тиеш.

8 сыйныф укучылары өчен татар әдәбиятыннан уку елы ахырында үткәрелә торган тест биремнәре 15 сорауны үз эченә алган 3 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлектәге биремнәр лирик яки лиро-эпик әсәргә, аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнә. Алар укучыларның лирик яки лиро-эпик әсәргә яки шагыйрь иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, шигъри әсәрләргә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тота. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә.

Икенче бүлектәге биремнәр проза яки драма әсәренә һәм аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнә. Алар укучыларның эпик яки драматик әсәргә яки әдип иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, проза яки драма әсәрләренә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тота. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә.

Өченче бүлектәге биремнәр 5-8 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап язуга йөз тота. Алар аерым әсәрләргә яки әдипләр иҗатына бәйле сорауларны үз эченә ала. Ике сорауның сайлап алып БЕРСЕНӘ генә җавап бирү сорала. Эшнең мондый эзлеклелектә оештырылуы укучының әсәргә сюжет-композицион, тема-проблема, тел-стиль ягыннан бәя бирү, үз фикерен җиткерү мөмкинлекләрен ачыкларга ярдәм итә.

**4. Эчтәлекнең, элементларына карап, биремнәргә бүленеше**

Укучыларның татар әдәбиятыннан белем дәрәҗәсен мониторинглау эше буларак тәкъдим ителгән тестлар эчтәлек ягыннан 7 өлешкә (кодификатордан карагыз) бүленгән кодификаторга нигезләнеп эшләнгән. Кодификатордагы “Әдәбият теориясе” өлешенә нигезләнеп, тестлардагы биремнәргә аерым теоретик төшенчә һәм терминнар кертелә. 3 бүлектә әдәби барыштагы аерым әдәби-тарихи чорлардан тематикага бәйле әдәби әсәрләр урын ала:

- Урта гасыр татар әдәбияты;
- XIX гасыр әдәбияты;
- XX йөз башы әдәбияты.

Тест биремнәрендә, үрнәк программага бәйле төстә, әлеге блоклардагы әсәрләргә һәм теоретик төшенчәләргә бәйле сораулар урын ала.

Сорауларның саны материалның мәктәптә өйрәнелү дәрәҗәсенә, күләменә һәм укучыларның яшь үзенчәлегенә карап билгеләнә.

Тест биремнәре түбәндәге бүлекләр кысасында төзелде: әдәбият тарихы, әдәби төр яки жанр, әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм формасы, сюжет-композиция, хронотоп, герой бирелеше, тел-сурәтләү чаралары. Теоретик биремнәр, әдәби әсәрләр әлеге сыйныф өчен үрнәк программада тәкъдим ителгән теоретик базага таянып сайланган.

Эшнең эчтәлеге һәм төзелеше укучының әдәбияттан алган белемнәрен (әдәбият тарихы һәм теориясе) бәяләргә мөмкинлек бирә:

– әдәби текстка төр һәм җанр үзенчәлекләреннән чыгып анализ ясый белүен;

– әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып алуын;

– төрле характерда үз фикерен җиткерә алуын;

– әдәби әсәрнең темасын, идеясен, автор күтәргән проблемаларны дөрес билгели алуын, геройга характеристика бирү мөмкинлеген;

– әдәби әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын билгели алуын;

– әсәрләргә язма интерпретация (шәрехләмә) бирү үзенчәлеген;

– әдәби факт һәм күренешләрне истә калдыруын;

– әсәрдә автор позициясен билгели алуын;

– укылган әсәргә карата үз мөнәсәбәтен язма формада бирә алуын.

Тестта өч төрле бирем кулланыла: ябык (А), ачык (В), киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәр (С).

| Биремнәрнең типлары | Тесттагы гомуми саны | Бирем номеры |
|---|---|---|
| Ябык тест | 8 | 1,2,3,4,8,9,10,11 |
| Бер сүз яки сүзтезмә белән җавап бирү тестлары / яки эзлеклелеккә салуга / яки сайлап алуга бәйле тестлар | 4 | 5, 7, 12, 14 |
| Тәңгәлләштерү тестлары | 2 | 6,13 |
| Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәр | 1 | 15 (15.1, 15.2) |

**5. Биремнең катлаулылык дәрәҗәсенә карап бүленеше**

Тестларда катлаулылыгы ягыннан өч төрле бирем тәкъдим ителә: 1 нче һәм 2 нче бүлектә бирелгән 8 (1 – 4; 8 – 11) гади, 6 бирем (5 – 7; 12 – 14) өлешчә катлауландырылган, 3 нче бүлектәге бирем катлаулы бирем дип санала. Киңәйтелгән җавап бирү барышында биремнең **б е р с е н  г е н ә** сайлап алу һәм шуңа җавап язу мөмкинлеге бирелә. Бу очракта укучы, мөстәкыйль рәвештә, әдәби темага эчтәлеге белән туры килгән, мәгънәви яктан эзлекле текст яза белүен, аудиотекст белән эшли алуын күрсәтергә тиеш.

**6. Аерым биремнәрне  һәм тулаем эшне бәяләү.**

Эшнең 1 нче һәм 2 нче бүлекләрендәге кыска җавапны таләп иткән ачык һәм ябык тестларга дөрес җавап  **1 балл** белән бәяләнә.

Киңәйтелгән җавапны бәяләү барышында “фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы” һәм “сөйләм нормаларына туры килүе” критерийлары үзәккә куела. Шулай итеп, 5-8 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап таләп иткән биремгә дөрес җавабы өчен укучы **өч балл** ала.

**7. Тестларны башкару өчен  45 минут вакыт бирелә.**

Эшнең  беренче һәм икенче бүлекләрендәге тестларга җавап бирү  өчен  – 25 минут, С биремен үтәүгә 20 минут вакыт күздә тотыла.

## Кодификатор

Рус телендә телендә гомуми белем бирү мәктәпләренең 5-9 нчы сыйныф татар укучыларына татар әдәбиятыннан тестлар уздыру өчен әзерлек дәрәҗәсенә куелган таләпләр һәм эчтәлек элементларының кодификаторы (алга таба -  Кодификатор) – уку елы башында һәм уку елы ахырында  укучыларның  предмет буенча белем дәрәҗәсен бәяләү тестларына КҮМ эчтәлеген билгеләүче документларның берсе.

Кодификаторда Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән үрнәк белем бирү программасына кертелмәгән әсәрләр һәм әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр чагылыш тапмый.

Бу документ уку елы башында һәм уку елы ахырында 5-9 нчы сыйныфларда татар әдәбиятыннан белем дәрәҗәсен бәяләү тестларына КҮМ төзү өчен нигез булып тора, шуңа да уку материалын гомумиләштерү һәм системалаштыру принципларыннан гыйбарәт.

### I БҮЛЕК. Татар әдәбиятыннан тикшерелә торган теоретик база һәм әсәрләр исемлеге.

| Бүлек коды | Контроль-үлчәү | Контроль-үлчәү материалларына нигезләнеп |
|---|---|---|

| | материалының коды | бәяләнүче берәмлекләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| ***1*** | | ***Әдәбият теориясе*** |
| | 1.1 | Сүз сәнгате буларак матур әдәбият. Халык авыз иҗаты, фольклор жанрлары. |
| | 1.2 | Әдәби барыш. Әдәбият тарихы. |
| | 1.3 | Әдәби образ. Образлар системасы. Образларның төрләре. Персонаж. Характер. Тип. Автор-хикәяләүче. Автор образы. Лирик герой. |
| | 1.4 | Деталь. Символ. Эзоп теле. |
| | 1.5 | Эчтәлек һәм форма. Тема. Проблема. Идея. Автор позициясе. |
| | 1.6 | Шартлылык. |
| | 1.7 | Әдәби-тарихи процесс. Әдәби юнәлешләр һәм агымнар: реализм, романтизм, модернизм, мәгърифәтчелек реализмы, тәнкыйди реализм, социалистик реализм, гыйсъянчылык. |
| | 1.8 | Әдәби төрләр: проза (эпик төр), лирика, драма; төрара формалардан лиро-эпика. Әдәби жанрлар: хикәя, повесть, роман; гражданлык лирикасы, күңел лирикасы, пейзаж лирикасы, фәлсәфи лирика; поэма, баллада, нәсер; комедия, трагедия, драма. |
| | 1.9 | Конфликт. Сюжет һәм сюжет элементлары: экспозиция, төенләнеш, кульминация, чишелеш, эпилог. Сюжеттан тыш элементлар. Мотив. |
| | 1.10 | Әдәби әсәр композициясе, композицион алымнар. |
| | 1.11 | Пафос, аның төрләре. Сурәтләнгән дөнья (портрет, пейзаж). Геройның сөйләменә характеристика: диалог, монолог. |
| | 1.12 | Хронотоп. |
| | 1.13 | Психологизм, алымнары. |
| | 1.14 | Сатира, юмор, ирония, фарс. |
| | 1.15 | Әдәби әсәрдә тел-сурәтләү чаралары: лексик чаралар (синоним, омоним, антоним, фразеологизм һ.б.), фоник чаралар (аллитерация, ассонанс һ.б.), стилистик чаралар (инверсия, кабатлау, антитеза һ.б.), троплар (чагыштыру, метафора, метонимия, аллегория, эпитет, сынландыру һ.б.). Риторик сорау, риторик өндәү, риторик эндәш. |
| | 1.16 | Стиль. |
| | 1.17 | Шигырь төзелеше системалары: силлабик. Ритм. Рифма. Строфа. |
| ***2*** | | ***Халык авыз иҗаты*** |
| | 2.1 | “Иске кара урман”, “Биючеләр көе”. |
| | 2.2 | “Өч кыз”, “Акбүре”, “Хәйләкәр Төлке” әкиятләре. |
| | 2.3 | “Җил иясе җил чыгара”, “Тавык” мифлары. |

| | | |
|---|---|---|
| | 2.4 | “Зөһрә кыз”, “Шәһәр нигә Казан дип аталган”, “Тургай моңы” риваятьләре. |
| | 2.5 | “Сак-Сок” бәете. |
| ***3*** | | ***Урта гасыр татар әдәбияты*** |
| | 3.1 | Кол Гали. “Кыйссаи-Йосыф” поэмасы. |
| | 3.2 | “Идегәй” дастаны. |
| | 3.3 | С.Сараи.“Сөһәйл вә Гөлдерсен” поэмасы. |
| | 3.4 | Кол Шәриф. “Гафил торма” шигыре. |
| | 3.5 | М.Колый. Хикмәтләр. |
| | 3.6 | Г.Утыз Имәни. “Гыйлемнең өстенлеге турында”, “Егет булу турында”, “Кәсеп турында”, “Татулык турында”, “Гомер итү турында”, “Үгет турында” шигырьләре. |
| ***4*** | | ***XIX гасыр әдәбияты*** |
| | 4.1 | Г.Кандалый. “Сәхипҗәмал” поэмасы. |
| | 4.2 | К.Насыйри. “Кырык бакча” җыентыгы, “Әбугалисина” повесте. |
| | 4.3 | М.Акъегет. “Хисаметдин менла” әсәре. |
| | 4.5 | Г.Ильяси. “Бичара кыз” пьесасы. |
| | 4.6 | Г.Исхакый. “Өч хатын берлән тормыш” драмасы. |
| ***5*** | | ***XX йөз башы әдәбияты*** |
| | 5.1 | Г.Тукай. “Милләткә”, “Тәәссер”, “Милли моңнар”, “Туган авыл”, “Туган җиремә”, “Пар ат”, “Җәйге таң хатирәсе” шигырьләре, “Исемдә калганнар” повесте, “Шүрәле” поэмасы. |
| | 5.2 | Дәрдемәнд “Кораб”, “Видагъ”, “Кил, өйрән” шигырьләре. |
| | 5.3 | С.Рәмиев. “Таң вакыты” шигыре. |
| | 5.4 | Н.Думави. “Син – кеше” шигыре. |
| | 5.5 | Ф.Әмирхан. “Хәят”повесте, “Ай өстендә Зөһрә кыз” хикәясе. |
| | 5.6 | Г.Исхакый. “Сөннәтче бабай” повесте. |
| | 5.7 | Ш.Камал. “Буранда” хикәясе. |
| | 5.8 | Н.Думави. “Яшь ана” хикәясе. |
| | 5.9 | Г.Рәхим. “Яз әкиятләре” хикәясе. |
| | 5.10 | Г.Камал. “Беренче театр” пьесасы. |
| | 5.11 | М.Фәйзи. “Галиябану” драмасы. |
| ***6*** | | ***XX гасыр (1920-1990 нче еллар) әдәбияты*** |
| | 6.1 | Г.Исхакый. “Көз” повесте. |
| | 6.2 | Г.Ибраһимов. “Казакъ кызы” романы, “Алмачуар” хикәясе. |
| | 6.3 | Ф.Әмирхан. “Шәфигулла агай” хикәясе. |
| | 6.4 | Г.Кутуй. “Тапшырылмаган хатлар” повесте. |
| | 6.5 | Һ.Такташ. “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасы, “Әй, җырлыйсы килә шушы җырны” шигыре. |

| | | |
|---|---|---|
| | 6.6 | М.Җәлил. “Җырларым”, “Ирек”, “Кошчык”, “Кичер, илем”, “Төрмәдә төш”, “Кызыл ромашка” шигырьләре, “Сандугач һәм чишмә” балладасы. |
| | 6.7 | Ф.Кәрим. “Кыр казы”, “Ватаным өчен”, “Сибәли дә сибәли”, “Бездә яздыр” шигырьләре. |
| | 6.8 | Х.Туфан. «Каеннар сары иде”, “Иртәләр җитте исә”, “Гөлләр инде яфрак яралар”, “Кайсыгызның кулы җылы?” шигырьләре. |
| | 6.9 | Г.Кутуй. “Сагыну” нәсере. |
| | 6.10 | Ә.Еники. “Әйтелмәгән васыять” повесте, “Кем җырлады?”, “Матурлык” хикәяләре. |
| | 6.11 | Ф.Хөсни. “Йөзек кашы” повесте. |
| | 6.12 | И.Гази. “Кояш артыннан киткән тургай”, “Ак сирень” хикәяләре. |
| | 6.13 | Ә.Фәйзи. “Тукай” романы (өзекләр). |
| | 6.14 | Ш.Маннур. “Муса” романы (өзекләр). |
| | 6.15 | Г.Бәширов. “Туган ягым – яшел бишек” повесте. |
| | 6.16 | А.Гыйләҗев. “Өч аршын җир” повесте. |
| | 6.17 | Н.Фәттах. “Итил суы ака торур” романы. |
| | 6.18 | Ф.Яруллин. “Җилкәннәр җилдә сынала” повесте, “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” шигыре, “Кояштагы тап” хикәясе. |
| | 6.19 | С.Хәким. “Бу кырлар, бу үзәнннәрдә”, “Тукайга”, шигырьләре. |
| | 6.20 | М.Мәһдиев. “Без – кырык беренче ел балалары” повесте. |
| | 6.21 | Р.Фәйзуллин. “Нюанслар иле” шигырьләр җыентыгыннан: “Көзге яңгыр”, “Язгы кәеф”, “Чынлык”, “Вакыт” шигырьләре, “Туган тел турында бер шигырь” шигыре, “Гадиләргә гимн”, “Сәйдәш” поэмалары. |
| | 6.22 | Ш.Галиев. “Пәрәмәч”, “Сәер кеше”, “Һәркем әйтә дөресен”, “Тагын бер рәхмәт” шигырьләре. |
| | 6.23 | Н.Арсланов. “Халкыма” шигыре. |
| | 6.24 | Р.Гаташ. “Татар китабы” шигыре. |
| | 6.25 | Р.Харис. “Сабантуй”, “Ак сөлге”, “Кеше кайчан матур була” шигырьләре. |
| | 6.26 | Зөлфәт. “Тамыр көлләре”, “Тылсым” шигырьләре. |
| | 6.27 | М.Әгъләмов. “Каеннар булсаң иде”, “Учак урыннары”, “Матурлык минем белән” шигырьләре. |
| | 6.28 | Г.Афзал. “Матурлык эзлим”, “Без – татарлар” шигырьләре. |
| | 6.29 | Р.Вәлиева. “Ватаным”, “Гүзәл җирем” шигырьләре. |
| | 6.30 | Т.Миңнуллин. “Дуслар җыелган җирдә”, “Әлдермештән Әлмәндәр” драмалары, “Гафият турында әкият” пьесасы. |
| | 6.31 | Р.Мөхәммәдиев.”Беренче умырзая” повесте. |
| ***7*** | | ***Хәзерге татар әдәбияты (1990 – 2020 нче еллар)*** |

| | | |
|---|---|---|
| | 7.1 | М.Галиев. “Җиңәсем килде” хикәясе, “Чатыр тау җиле” әсәре. |
| | 7.2 | А.Әхмәтгалиева. “Кайтаваз” хикәясе. |
| | 7.3 | Р.Галиуллин. “Сәлам” хикәясе, “Юлларда ак җил иде” әсәре. |
| | 7.4 | Р.Миңнуллин. “Татарларым”, “Әни, мин көчек күрдем”, “Олы булсам...”, “Бүренең кешеләр белән дуслашуы турында кечкенә әкият” шигырьләре. |
| | 7.5 | М.Мирза. “Көздә бер мәл” шигыре. |
| | 7.6 | Л.Лерон. “Фашист очып үтте” шигыре. |
| | 7.7 | Р. Рәкыйпов. “Мин яратам сине, Татарстан” шигыре. |
| | 7.8 | Г.Морат. “Туган тел” |

## II БҮЛЕК. Татар әдәбиятыннан тикшерелә торган әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр исемлеге

| **Таләпнең коды** | **Әзерлек дәрәҗәсенә таләпләр** |
|---|---|
| | ***Белергә / аңларга*** |
| 1.1 | Сүз сәнгате буларак матур әдәбиятның үзенчәлекләрен. |
| 1.2 | Тәкъдим ителгән әсәрләрнең эчтәлеген. |
| 1.3 | Тәкъдим ителгән авторларның тормыш һәм иҗат биографиясен. |
| 1.4 | Әдәби-тарихи барышны һәм аның төп әдәби-тарихи үзенчәлекләрен. |
| 1.5 | Тәкъдим ителгән әсәрләргә эчтәлек һәм форма берлегендә анализ үзенчәлекләрен. |
| 1.6 | Төп теоретик төшенчәләрне. |
| **2** | ***Эшли белергә*** |
| 2.1. | Әсәрнең эчтәлеген аңлата белергә. |
| 2.2. | Әдәби әсәрне анализлый белергә: әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып алырга, әсәрнең темасын, идеясен, автор күтәргән проблемаларны дөрес билгеләргә, геройга характеристика бирергә, әсәрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен, иҗат принципларын, әсәрдә кулланылган тел-сурәтләү чараларын билгеләргә. |
| 2.3. | Әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни фонда бәяли алырга. |
| 2.4. | Тәкъдим ителгән әсәрне шул чор әдәби процессы белән бәйләнештә бәяли алырга, әдәби факт һәм күренешләрне чагыштыра белергә. |
| 2.6. | Әдәби текстка төр һәм жанр үзенчәлекләреннән чыгып бәя бирә алырга. |
| 2.7. | Әдәби әсәрләрне чагыштыра белергә. |
| 2.8. | Әсәрдә автор позициясен, автор стиленең үзенчәлеген, кулланылган тел-сурәтләү чараларының төрләрен, функцияләрен, әдәби алымнарны билгели алырга. |
| 2.9 | Үз мөнәсәбәтен нигезле итеп дәлилле алырга. |

| | |
|---|---|
| 2.10 | Укылган әсәргә карата үз мөнәсәбәтен язма формада бирә алырга. |
| **3.** | ***Алган белем һәм күнекмәләрне гамәли эштә һәм көндәлек тормышта куллану*** |
| 3.1. | Татар теленең әдәби нормаларына таянып, эзлекле текст язарга. |
| 3.2. | Әңгәмә һәм бәхәсләрдә катнашырга. |

## Аңлатма

Татар әдәбиятыннан уку елы ахырында тестлар уздыру материалларының күрсәтмә варианты укучыларга һәм укытучыларга йөз тотып төзелде. Шуны истә тотарга кирәк: әлеге вариант тәкъдим ителәчәк биремнәрне тулысынча чагылдырмый. Аның төп максаты – укучыларга тест эшләүгә мөстәкыйль әзерләнү өчен юнәлеш бирү.

Күрсәтмә вариант укучыларда биремнәрнең структурасы, күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм укытучыларда бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый, укучыларга татар әдәбиятыннан тестларга әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итә.

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Имтихан эшен башкару өчен 45 минут вакыт бирелә. Татар әдәбиятыннан тест уздыру биремнәре 15 биремне үз эченә алган 3 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлектәге биремнәр лирик яки лиро-эпик әсәргә, аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның лирик яки лиро-эпик әсәргә яки шагыйрь иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, шигъри әсәрләргә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә.

Икенче бүлектәге биремнәр проза яки драма әсәренә һәм аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның эпик яки драматик әсәргә яки әдип иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, проза яки драма әсәрләренә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә. Җавап бирү барышында төгәл эшләү һәм күрсәтмәләрне игътибар белән уку таләп ителә.

Өченче бүлектәге биремнәр 5-8 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап язуга йөз тота. Ике сорауның сайлап алып БЕРСЕНӘ генә җавап бирү сорала. Җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә формалаштыру кирәк. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Беренче, икенче бүлекләрдә сораугa төгәл җавап табылмый икән, авырлык тудырган сорауларны калдырып торырга, өченче өлештәге биремне үтәргә, эшләнми калган биремнәргә соңыннан әйләнеп кайтырга мөмкин.

Катлаулылык дәрәҗәсенә карап, һәр биремгә бер яки аннан артык балл куела, ахырда бөтен баллар бергә кушылып, нәтиҗә чыгарыла.

**Уңышлар телибез!**

**1 вариант**

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

| |
|---|
| **1-4 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.** |

1. «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә Йосыфның яраткан кызы кем исемле?
   1) Динә
   2) Зөләйха
   3) Гөлдерсен

2. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәренең авторы кем?
   1) Г.Кандалый
   2) Сәйф Сараи
   3) Кол Шәриф

3. Кайсы әсәр дастан жанрында?
   1) «Идегәй»
   2) «Сәхипҗәмал»
   3) «Егет булу турында»

4. Иҗатында символлар күп кулланылган XX йөз башы татар шагыйре:
   1) С.Рәмиев
   2) Дәрдемәнд
   3) Г.Тукай

| |
|---|
| **5 – 7 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.** |

5. Татар реалистик поэзиясенә нигез салучы язучы:

   Җавап: ________________

6. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Кыйссаи Йосыф» | 1) Кол Шәриф |
| Ә) «Гафил торма» | 2) Халык авыз иҗаты |
| Б) «Идегәй» | 3) Кол Гали |

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

7. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *лирик төр, лиро-эпик төр, халык авыз иҗаты жанры* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Сөһәйл вә Гөлдерсен»
2) «Гафил торма»
3) «Идегәй»

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**8 – 11 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

8. XX йөз башында яңа чор милли темага күп әсәрләр язган, татарның инкыйразы өчен борчылган язучы:

1) Габдулла Тукай
2) Дәрдемәнд
3) Г.Исхакый

9. «Хисаметдин менла» романында төп герой:

1) Хәнифә
2) Хисаметдин
3) Бикбулат хәзрәт

10. Татар әдәбиятында мәгърифәтчел проза әсәрләре языла башлаган чор:

1) XX йөз башы
2) XIX йөз
3) XVIII йөз урталары

11. Ф.Әмирханның «Хәят» повестенда Хәятнең кичерешләре нинди алым белән бирелә?

1) психологизм
2) символлаштыру
3) лиризм

**12-14 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

12. Кешенең эчке дөньясын ачуга хезмәт итә торган алымнар берлеге; язучының кеше күңеленә үтеп керү, аның халәт-кичерешен сурәтләү осталыгы. Ф.Әмирханның «Хәят» повестенә Хәятнең дачада Михаил белән очрашудан соңгы кичерешләрен чагылдыру ысулы:

Җавап: _____________

13. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Сөннәтче бабай» | 1) М.Акъегетзадә |
| Ә) «Хисаметдин менла» | 2) Г.Утыз Имәни |
| Б) «Татулык турында» | 3) Гаяз Исхакый |

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

14. «Галиябану», «Кырык бакча», «Сөннәтче бабай» әсәрләре арасыннан драма жанрында иҗат ителгәнен сайлап алып языгыз:

Җавап: ________________

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**15.1 һәм 15.2. биремнәренә 5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.**

15.1. Г.Тукайның «Милли моңнар» шигырен тыңлагыз һәм лирик геройга хас сыйфатларны языгыз.

15.2. Ф. Әмирханның «Хәят» повестеннан өзекне тыңлагыз. Хәятне бу өзектән чыгып ничек характерлар идегез? Дәлилләгез.

## ҖАВАПЛАР

### Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 2 |
| 3 | 1 |
| 4 | 2 |
| 5 | ГАБДУЛЛА ТУКАЙ |
| 6 | 312 |
| 7 | 213 |
| 8 | 3 |
| 9 | 2 |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | ПСИХОЛОГИЗМ |
| 13 | 312 |
| 14 | ГАЛИЯБАНУ |

### Киңәйтелгән җавапларны (5-8 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |

| | |
|---|---|
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

## 2 вариант

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

**1-4 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

1. «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә Йосыфның яраткан кызы кем исемле?
    1) Динә
    2) Зөләйха
    3) Гөлдерсен

2. «Сөһәйл вә Гөлдерсен» әсәренең авторы кем?
    1) Г.Кандалый
    2) Сәйф Сараи
    3) Кол Шәриф

3. Кайсы әсәр дастан жанрында?
    1) «Идегәй»
    2) «Сәхипҗәмал»
    3) «Егет булу турында»

4. Иҗатында символлар күп кулланылган XX йөз башы татар шагыйре:
    1) С.Рәмиев
    2) Дәрдемәнд
    3) Г.Тукай

**5 – 7 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

5. Татар реалистик поэзиясенә нигез салучы язучы:

Җавап: ________________

6. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Кыйссаи Йосыф» | 1) Кол Шәриф |
| Ә) «Гафил торма» | 2) Халык авыз иҗаты |
| Б) «Идегәй» | 3) Кол Гали |

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

7. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *лирик төр, лиро-эпик төр, халык авыз иҗаты жанры* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Сөһәйл вә Гөлдерсен»
2) «Гафил торма»
3) «Идегәй»

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**8 – 11 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

8. XX йөз башында яңа чор милли темага күп әсәрләр язган, татарның инкыйразы өчен борчылган язучы:

1) Габдулла Тукай
2) Дәрдемәнд
3) Г.Исхакый

9. «Хисаметдин менла» романында төп герой:

1) Хәнифә
2) Хисаметдин
3) Бикбулат хәзрәт

10. Татар әдәбиятында мәгърифәтчел проза әсәрләре языла башлаган чор:

3) XX йөз башы

4) XIX йөз

3) XVIII йөз урталары

11. Ф.Әмирханның «Хәят» повестенда Хәятнең кичерешләре нинди алым белән бирелә?

1) психологизм
2) символлаштыру
3) лиризм

**12-14 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

12. Кешенең эчке дөньясын ачуга хезмәт итә торган алымнар берлеге; язучының кеше күңеленә үтеп керү, аның халәт-кичерешен сурәтләү осталыгы. Ф.Әмирханның «Хәят» повестенә Хәятнең дачада Михаил белән очрашудан соңгы кичерешләрен чагылдыру ысулы:

Җавап: _____________

13. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Сөннәтче бабай» | 1) М.Акъегетзадә |
| Ә) «Хисаметдин менла» | 2) Г.Утыз Имәни |
| Б) «Татулык турында» | 3) Гаяз Исхакый |

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

14. «Галиябану», «Кырык бакча», «Сөннәтче бабай» әсәрләре арасыннан драма жанрында иҗат ителгәнен сайлап алып языгыз:

Җавап: ________________

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**15.1 һәм 15.2. биремнәренә 5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.**

15.1. Г.Тукайның «Милли моңнар» шигырен тыңлагыз һәм лирик геройга хас сыйфатларны языгыз.

15.2. Ф. Әмирханның «Хәят» повестеннан өзекне тыңлагыз. Хәятне бу өзектән чыгып ничек характерлар идегез? Дәлилләгез.

## ҖАВАПЛАР

### Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 2 |
| 3 | 1 |
| 4 | 2 |
| 5 | ГАБДУЛЛА ТУКАЙ |
| 6 | 312 |
| 7 | 213 |
| 8 | 3 |
| 9 | 2 |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | ПСИХОЛОГИЗМ |
| 13 | 312 |
| 14 | ГАЛИЯБАНУ |

### Киңәйтелгән җавапларны (5-8 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата | **1** |

| | |
|---|---|
| күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **3. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |